ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** Зеленодольск шәһәре **КАРАР**

**30.07.2019** **№1587**

«2015-2021 елларга Зеленодольск муниципаль районында коррупциягә каршы сәясәтне гамәлгә ашыру» муниципаль программасына үзгәрешләр кертү турында

Зеленодольск муниципаль районында коррупциягә каршы тору системасын камилләштерү максатларында һәм Россия Федерациясе Президентының «2018-2020 елларга коррупциягә каршы торуның милли планы турында» 2018 елның 29 июнендәге 378 номерлы Указын үтәү йөзеннән Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2015 елның 5 мартындагы «2015-2020 елларга Зеленодольск муниципаль районында коррупциягә каршы сәясәтне гамәлгә ашыру» муниципаль программасын раслау турында» гы 477 номерлы карарына (Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2016 елның 30 маендагы 1432 номерлы, 2016 елның 6 августындагы 1603 номерлы, 2018 елның 1 октябрендәге 1936 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән) әлеге карарга кушымта нигезендә үзгәрешләр кертергә.
2. ЯҮМР Советы Аппаратының җәмәгатьчелек һәм ММЧ белән элемтә бүлеге җитәкчесе Д.С.Анисимовка әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында Зеленодольск муниципаль районы сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

Җитәкче Д.А. Сапожников

Кушымта
Зеленодольск муниципаль
районы Башкарма комитеты
карарына

30.07.2019 № 1587

**Программаның паспортында «Күләме һәм финанслау чыганаклары» 2нче пунктының графасын түбәндәге эчтәлекле текст белән тулыландырырга:** «Әлеге программаны гамәлгә ашыруга бәйле чараларны финанслау Зеленодольск муниципаль районы бюджетында расланган ассигнованиеләр чикләрендә тиешле финанс елына гамәлгә ашырыла. Программаны тормышка ашыруга тотылган акчаларның күләме район бюджеты, Зеленодольск муниципаль районы территориясендә инфляция процесслары һәм икътисадый вәзгыять мөмкинлекләреннән чыгып төгәлләштерелергә һәм төзәтмәләр кертелергә мөмкин».